Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2025 елның 13 марты №126

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге «муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен яңа редакциядә раслау турында»2017 елның 14 июнендәге 55 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы прокуратурасының 2025 елның 31 гыйнварындагы Прдп-20-25 номерлы протесты һәм «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законына таянып , Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хайваннарны исәпкә алуны гамәлгә ашыру кагыйдәләрен һәм индивидуаль яисә төркемләп маркировкаланырга һәм исәпкә алынырга тиешле хайваннар төрләре исемлеген, хайваннарны индивидуаль яисә төркемләп маркировкалау һәм исәпкә алу очракларын, шулай ук хайваннарны исәпкә алуны гамәлгә ашыру срокларын раслау турында» 2023елның 5 апрелендәге 550 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен яңа редакциядә раслау турында» 2017 елның 14 июнендәге 55 номерлы карарына(алга таба - Кагыйдә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кагыйдәләрнең 153 пунктын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Яңасала авылы, Үзәк,1 йорт ;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Шәпкә авылы, Клуб урамы, 14 һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль

районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Кама Тамагы муниципаль районы
Яңасала авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Яңасала авыл җирлеге Советы рәисе И.Х.Шигабеев